РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«22» июль 2021 г. г. Альметьевск № 63

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турында нигезләмә хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы 6 өлеше, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 26 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мелкәте һәм мелкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта ).

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү формасын расларга (2 нче кушымта).

3. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Заказ № 2625

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Парфилова Н.В.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Советының 2021 елның
22 июлендәге 63 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм бу белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турында

НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге Нигезләмә белән Әлмәт муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәр, мелкәт һәм мелкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрен Әлмәт муниципаль районы сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - сайт) урнаштыру, шулай ук әлеге белешмәләрне аларның соралуларына бәйле рәвештә бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына (алга таба - массакүләм мәгълүмат чаралары) бирү тәртибе билгеләнә.

2. Сайтта түбәндәгеләр урнаштырыла һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында түбәндәге белешмәләр бирелә:

а) Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе, аның ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының милек хокукында булган объектларның һәркайсының урнашу төре, мәйданы һәм иле күрсәтелгән күчемсез мөлкәт объектлары исемлеге;

б) Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесенең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының милек хокукындагы төре һәм маркалары күрсәтелгән транспорт чаралары исемлеге;

в) Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесенең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының декларацияләнгән еллык кереме.

3. Сайтта урнаштырыла торган һәм массакүләм мәгълүмат чараларына керемнәр, мөлкәт һәм мелкәти характердагы йөкләмәләр турында бастырып чыгару өчен бирелә торган белешмәләрдә түбәндәгеләрне күрсәтү тыела:

а) Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесенең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, аталган затларга милек хокукындагы мөлкәте һәм аларның мелкәти характердагы йөкләмәләре турында (әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән гайре) башка белешмәләр;

б) Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесенең хатынының (иренең) һәм балаларының һәм гаиләсенең башка әгъзаларының персональ күрсәткечләре;

в) Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесенең, аның хатынының (иренең), балаларның һәм гаиләнең

башка әгъзаларының яшәү урынын, почта адресын, телефонын һәм коммуникацияләрнең башка индивидуаль чараларын билгеләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар;

г) Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесенең, аның хатынының (иренең), балаларның, гаиләнең башка әгъзаларының милек хокукында яисә алардан файдаланууда булган күчемсез мөлкәт объектларының урнашу урынын билгеләргә мемкинлек бирә торган мәгълүматлар;

д) дәүләт серенә кертелгән яисә конфиденциаль булган мәгълүмат.

4. Әлеге тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән керемнәр, чыгымнар, мелкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе эш вазыйфасын башкарган бөтен чорда, аның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мелкәти характердагы йекләмәләре турында белешмәләре, хезмәткәр эш вазыйфасы биләгән органның яисә оешманың сайтында урнаштырыла һәм аларны биргән көннән алып 14 эш көне эчендә ел саен яңартыла.

5. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән керемнәр, мелкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан аларны бирү өчен билгеләнгән срок тәмамланган кеннән алып 14 эш кене эчендә сайтка урнатырыла.

6. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты:

а) массакүләм мәгълүмат чараларыннан сорау кергән көннән алып өч эш кене эчендә бу турында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесенә хәбәр итә;

б) массакүләм мәгълүмат чараларыннан сорау алынган кеннән алып җиде эш кене эчендә, әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне бирүне тәэмин итә, әгәр дә соралган белешмәләр сайтта булмаса.

7. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йекләмәләре турында белешмәләрне сайтта урнаштыруны һәм аларны бастырып чыгару өчен гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына тәкъдим итүне тәэмин итүче вазыйфаи затлар, әлеге Нигезләмәнең таләпләрен үтәмәгән, шулай ук дәүләт серенә кертелгән яисә конфиденциаль булган белешмәләрне фаш иткән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Советының 2021 елның
22 июлендәге 63 номерлы
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре һәм аларның гаилә әгъзаларының 20___ елның 1 гыйнварыннан 31 декабрьгә кадәр чорда керемнәр, мелкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында урнаштыру өчен

БЕЛЕШМӘЛӘР

| № п/п | | Декларация-еллык керем (сум.) | Милектә булган күчемсез милек объектлары | | | | Кулланышта булган күчемсез милек объектлары | | | Транспорт чаралары |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Объек төре | Милек төре | мәйданы (кв. м) | объект урнашкан ил | объект төре | мәйданы (кв. м) | объект урнашкан ил | төре, маркасы |
| | ФИО | | | | | | | | | |
| | хатыны( ире) | | | | | | | | | |
| | балигъ булмаган бала | | | | | | | | | |

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов